КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 25 май г.Казань № 736

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турында Татарстан Республикасы бердәм мәгълүматлар банкын формалаштыру хакында» 2010 ел, 22 апрель, 294 нче карары белән расланган Социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турында Татарстан Республикасы бердәм мәгълүматлар банкын формалаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турында Татарстан Республикасы бердәм мәгълүматлар банкын формалаштыру хакында» 2010 ел, 22 апрель, 294 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 8 май, 332 нче, 2023 ел, 4 сентябрь, 1067 нче, 2025 ел, 6 август, 569 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турында Татарстан Республикасы бердәм мәгълүматлар банкын формалаштыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:https://login.consultant.ru/link/?req=doc&base=RLAW363&n=48830&dst=100014

2.1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнарны һәм аларның гаиләләрен ачыклауны һәм алар белән шәхси профилактика эшен оештыруны тәэмин итә торган балигъ булмаганнарның кайгыртучысыз калуын һәм хокук бозуын профилактикалау буенча республика системасына (алга таба – профилактика системасы органнары һәм учреждениеләре) керә торган дәүләт хакимиятенең федераль органнарының һәм аларның территориаль органнарының, республика башкарма хакимият органнарының һәм Татарстан Республикасы учреждениеләренең, җирле үзидарә органнарының оператив эш итү һәм үзара хезмәттәшлек итү

системасын булдыру.»;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бердәм мәгълүмат банкына кертелә торган балигъ булмаганнар категорияләре

Бердәм мәгълүмат банкына түбәндәге балигъ булмаганнар категорияләре кертелә:

1) күзәтүчесезләр:

ата-аналары (законлы вәкилләре) аларны тәрбияләү, укыту һәм (яисә) матди карап тору, аларның сәламәтлеген саклау, аларның үз-үзләрен тотышын тикшереп тору бурычларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән һәм (яки) аларның үз-үзләрен тотышларына тискәре йогынты ясаган балигъ булмаганнар (шул исәптән ата-аналар тарафыннан алкоголь һәм спиртлы продукцияне явызларча куллануга, ата-аналар тарафыннан наркотик чаралар яисә психотроп матдәләрне табиб билгеләмичә куллануга, йә агулаучы матдәләр куллануга, сукбайлыкка, ата-аналарда психик тайпылыш булуга бәйле);

формаль булмаган берләшмәләрдә һәм җәмгыятькә каршы юнәлешле оешмаларда катнашучы балигъ булмаганнар;

«колумбайн» («скулшутинг») хәрәкәте тарафдарлары булган балигъ булмаганнар;

психологик көчләү, намусны һәм абруйны системалы рәвештә кимсетү, мыскыл итү, эзәрлекләү белән шөгыльләнүче балигъ булмаганнар;

2) сукбайлар (яшәү урыны һәм (яисә) тору урыны булмаган күзәтүчесезләр);

3) сукбайлык яисә теләнү белән шөгыльләнүчеләр;

4) ата-аналары (законлы вәкилләре) аларны җинаять кылуга яисә җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуга җәлеп иткән балигъ булмаганнар;

5) ата-аналары (законлы вәкилләре) алар белән каты мөгамәләдә булган (физик, психологик көч куллану, җенси кагылгысызлыкка һөҗүм) балигъ булмаганнар;

6) балигъ булмаганнар өчен социаль-тернәкләндерү үзәкләрендә, социаль приютларда, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга ярдәм күрсәтү үзәкләрендә, ачык типтагы махсус укыту-тәрбия учреждениеләрендә һәм социаль ярдәмгә һәм (яисә) тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен башка учреждениеләр булган затлар;

7) наркотик чаралар яки табиб билгеләмичә психотроп матдәләр кулланалар йә агулаучы матдәләр, алкогольле һәм спиртлы продукция кулланучылар;

8) административ җаваплылык чараларын куллануга китергән хокук бозучылар;

9) административ җаваплылык башланган яшькә җиткәнче хокук бозучылар;

10) җәзадан котылдыру акты нәтиҗәсендә, шулай ук балигъ булмаганны төзәтү тәрбия йогынтысының мәҗбүри чараларын куллану юлы белән мөмкин дип танылгач очракларда җинаять җаваплылыгыннан азат ителгәннәр;

11) җәмгыять өчен куркыныч эш кылучылар һәм җинаять җаваплылыгы башлана торган яшькә җитмәү сәбәпле яки психик тайпылыш белән бәйле булмаган психик үсештә артта калу нәтиҗәсендә җинаять җаваплылыгына тартылмаганнар;

12) Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексында каралган чик кую

чаралары сайланган җинаятьләр кылуда гаепләнүчеләр яисә шикләнелүчеләр;

13) җәа үтәүдән шартлы-вакытыннан алда азат ителгәннәр, амнистия турында акт нәтиҗәсендә яки кичерү белән бәйле җәзадан азат ителгәннәр, шулай ук хәл үзгәрүгә бәйле рәвештә җәзадан азат ителгәннәр;

14) җәза үтәүне кичектерү яки хөкем карарын үтәүне кичектерү бирелгәннәр;

15) җинаять-үтәтү системасы учреждениеләреннән, федераль иминлек хезмәте органнарының тикшерү изоляторларыннан азат ителгәннәр, ябык типтагы махсус укыту-тәрбия учреждениеләреннән кайтканнар, әгәр алар күрсәтелгән учреждениеләрдә булу чорында режим бозсалар, хокукка каршы гамәлләр кылсалар һәм (яки) азат ителгәннән (чыгарылганнан) соң социаль куркыныч хәлдә һәм (яисә) социаль ярдәмгә һәм (яисә) тернәкләндерүгә мохтаҗ булсалар;

16) зур булмаган яисә уртача авырлыктагы җинаять кылган өчен хөкем ителгәннәр һәм суд тарафыннан мәҗбүри тәрбия йогынтысын кулланып, җәзадан азат ителгәннәр;

17) шартлы рәвештә хөкем ителгәннәр, мәҗбүри эшләргә, төзәтү эшләренә яисә иректән мәхрүм итүгә бәйле булмаган җәзаның башка чараларына хөкем ителгәннәр;

18) үз-үзенә кул салуга омтылыш ясаганнар.»;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Бердәм банкка социаль куркыныч хәлдә булган ачыкланган балигъ булмаганнар, аларның гаиләләре турында мәгълүматлар бирүне гамәлгә ашыручы һәм алар белән индивидуаль профилактик эшне законнар белән каралган үз компетенцияләре чикләрендә уздыручылар бердәм мәгълүмат банкын төзүдә катнашучылар балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы субъектлары булып тора, алар гаиләләргә һәм социаль куркыныч хәлдәге балаларга социаль патронлаштыру ведомствоара системасына керә:

Татарстан Республикасы муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында балигъ булмаганнар эшләре, аларның хокукларын яклау комиссияләре;

хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү, социаль яклау, шул исәптән социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә идарәне гамәлгә ашыручы орган һәм аңа буйсынучы социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе;

мәгариф өлкәсендә идарәне гамәлгә ашыручы органнар һәм мәгариф оешмалары;

опека һәм попечительлек органнары;

яшәр эшләре буенча органнар, яшәр сәясәте учреждениеләре;

сәламәтлек саклау өлкәсендә идарәне гамәлгә ашыручы органнар һәм сәламәтлек саклау оешмалары;

эчке эшләр органнары;

җинаять-үтәтү системасы  оешмалары;

мәдәният, ял органнары һәм оешмалары;

спорт органнары һәм оешмалары;

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил.»;

4.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4.4. Мәгълүматларның бердәм банкы профилактика системасы органнары һәм

учреждениеләре тарафыннан бирелә торган белешмәләр нигезендә төзелә.

Төбәк дәрәҗәсендә бердәм мәгълүматлар банкының операторы булып «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының республика ресурс үзәге» дәүләт казна учреждениесе тора.

Муниципаль дәрәҗәдә бердәм мәгълүматлар банкы операторлары булып халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплексльы үзәкләре тора.

Бердәм мәгълүмат базасы «Татарстан Республикасында социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрне һәм балигъ булмаганнарны исәпкә алу һәм мониторинглау» мәгълүмат системасы аша төзелә һәм яңа ачыкланган социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаган балалар  һәм мәгълүматлар үзгәргәндә аларның гаиләләре, уздырыла торган тернәкләндерү чаралары һәм аларның нәтиҗәләре турында мәгълүмат кергән саен тулыландырыла.»;

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Татарстан Республикасында социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрне һәм балигъ булмаганнарны исәпкә алу һәм мониторинглау» мәгълүмат системасына керү мөмкинлеге бирелә:

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә - авыр тормыш хәлендә калган балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау механизмнарының нәтиҗәле эшләвенә өстәмә гарантияләр тәэмин итү һәм компетенция чикләрендә балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау өлкәсендәге бурычларны гамәлгә ашыру өчен;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә эшчәнлек алып баручы балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы субъектлары вазыйфаи затларына - компетенция чикләрендә бердәм мәгълүматлар банкы төзүдә катнашу өчен;

республика башкарма хакимият органнарының вазыйфаи затларына - балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре эшчәнлегенә ведомство контролен гамәлгә ашыру өчен;

эчке эшләр органнарының вазыйфаи затларына - социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре белән индивидуаль профилактик эш башкаруны оештыруны тикшереп тору өчен, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнарында, шәһәр округларында социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре белән индивидуаль профилактик эш башкару өчен;

Татарстан Республикасы прокуратурасының, Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнары прокуратураларының вазыйфаи затларына - балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре тарафыннан законнарның үтәлешенә прокурор күзәтчелеген гамәлгә ашыру өчен.»;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

5.4. «Татарстан Республикасында социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрне һәм балигъ булмаганнарны исәпкә алу һәм мониторинглау» мәгълүмат системасына керү шәхси теркәү күрсәткечләре (пароль һәм логин) буенча гамәлгә ашырыла.

Шәхси теркәү күрсәткечләре «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Республика ресурс үзәге» дәүләт казна учреждениесе тарафыннан бирелә:

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә - Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең язмача соратуы нигезендә;

бердәм мәгълүматлар банкы төзүдә катнашучыларга - Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетлары җитәкчеләренең язмасы соратулары нигезендә;

республика башкарма хакимият органнарының вазыйфаи затларына - республика башкарма хакимият органнары җитәкчеләренең (җитәкчеләр урынбасарларының) язмача соратулары нигезендә;

эчке эшләр органнарының вазыйфаи затларына - эчке эшләр органнары җитәкчеләренең (җитәкчеләр урынбасарларының) язмача соратулары нигезендә;

Татарстан Республикасы прокуратурасының, Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнары прокуратураларының вазыйфаи затларына - Татарстан Республикасы Прокурорының (Прокурор урынбасарының), Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнары прокурорларының язмача соратулары нигезендә.»;

әлеге Тәртипкә кушымтаны яңа редакциядәбәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин